РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ ИЗМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422052, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Измя, ул. Школьная, 9
тел. (84362) 49-1-32, (84362) 49-1-22

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЭЗМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422052, Татарстан Республикасы, Саба районы, Эзмә авылы, Мәктәп урамы, 9 йорт
тел. (84362) 49-1-32, (84362) 49-1-22

e-mail: Ism.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
04.06.2021

КАРАР
№14

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс үткәрү тәртибе турында 20.12.2012 елгы 33 номерлы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге Советы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 31.07.2020 елгы 268-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге Советы 20.12.2012 елгы 33 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 10 пунктның 3 пунктчасының 2 абзацында " хезмәт кенәгәсеннән” сүзләреннән соң “һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/rus/izma адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Эзмә авыл
җирлеге башлыгы

А.Р.Шәйхетдинов